ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 62^2 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең 3266,14 гектарлы урман-парк яшел поясын булдырырга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына Казан шәһәренең урман-парк яшел поясы чикләре буенча чикләрнең текстлы һәм график тасвирламасын, чикләрдәге әһәмиятле урыннарның географик координатлары исемлеген яисә Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры алып бару өчен билгеләнгән координатлар системасында әлеге урыннарның координатлары исемлеген үз эченә алган тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 24 декабре
№ 241-VI ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ